ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПОПОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ПОПОВКА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.01.2019 ел №1

Поповка авылы

Баулы муниципаль районы Поповка
авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең
гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә
торган хезмәтләр кыйммәтен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Җирләү һәм җирләү эше турында»гы 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы «Татарстан Республикасында «Җирләү һәм җирләү эше турында»гы Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында»гы карары, 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында»гы карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Поповка авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Поповка авыл җирлегендә, 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә, җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсмихокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Поповка авыл җирлегенең «Интернет» челтәрендәге сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2019 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземәйөклим.

Авыл җирлеге башлыгы С.А.Попов